Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы Зур Мәшләк авыл
җирлеге Советы

**КАРАР № 1**

Зур Мәшләк авылы 2023 елның 26 январе

Балык Бистәсе муниципаль районы
Зур Мәшләк авыл җирлеге башлыгының
2022 елгы хисабы һәм 2023 елга бурычлар турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 36 статьясындагы 5, 5.1 өлешләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 статьясындагы 7, 7.1 өлешләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Зур Мәшләк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Зур Мәшләк авыл җирлеге карар итте:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге башлыгы М.Г.Заһидуллинның 2022 елдагы хисабы һәм 2023 елга бурычлар турындагы хисабын игътибарга алырга.
2. 2023 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Зур Мәшләк авыл җирлеге җирле үзидарә органнары алдына түбәндәге бурычлар куярга :

-Зур Мәшләк торак пункты территориясендә энергия саклаучы лампаларны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү;
- Торак пунктны су белән тәэмин итү;
-Торак пункт юлларын ремонтлау, кышкы карап тору һәм хезмәтләр өчен түләү;
-Зиратларны барлап, чистартып тору.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга : Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авылы, Школьная урамы, 13А йорт; Югары Мәшләк авылы, Нариманова урамы, 24а йорт; Зур Мәшләк авылы, М.Горький урамы, 50 А йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Зур Мәшләә авыл җирлеге башлыгы М.Г.Заһидуллин